# Ислам нуры

اسلام نوری

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 23 (699) 12 декабрь 2019 ел (1441, Рабигуль-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Яхшылык итегез

Бер-берегездән көнләшмәгез, бачуланышмагыз, сүз үлчәшмәгез, бер-берегездән аерылып тормагыз. Ачу вакытында үз-үзегезне тота белегез. Рәнҗетүдән, процент алудан (риба) вә саранлык итүдән сакланыгыз, ялган, гайбәт, яла ягу сөйләмәгез. Сүз йөртмәгез, вәгъдәгезгә каршы килмәгез. Әманәткә хыянәт итмәгез, мөэмин кардәшләрегезне, хосусан үлекләрне сүкмәгез, ләгънәт кылмагыз, динсез дип сөйләмәгез, яман уй йөртүче булмагыз. Кеше көлдерер өчен сүз сөйләмәгез. Белешләрегезнең вә белеш түгелләрегезнең барчасына сәлам бирегез. Якын кардәшләрегездән аерылып тормагыз, фәкыйрьләргә яхшылык итегез. Кешеләр йоклаганда сез кайбер вакыт булса да намаз укыгыз. Үзегез, ата вә аналар, әби вә бабайлар, туганнарыгыз, ирләрегез вә хатыннарыгыз, кыямәт көненә кадәр киләчәк нәсел-нәсәпләрегезнең иман белән дөньядан кичүләре хакында дога кылыгыз. Кабул булса-булмаса да дога кылу — Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә ялвару — гыйбадәттер, шуның өчен бу эшне дәвам итегез, хосусан күңел төшкән вакытларны файдалана белегез. Ләкин үзегез белән Аллаһы Тәгалә арасына



һичбер кешене уртага куймагыз, һәр хаҗәтегезне тугры үз телегез белән һәм ихлас күңелегез белән сорагыз. Ихлас соралган догалар — бүген булмаса, бер көнне кабул булыр, моны исә шөбһәсез дөрес белегез.

**(Риза ФӘХРЕДДИН. “Әхлак гыйлеме”ннән)**

## ТР МДН хәбәр итә



Рабигуль-ахир аеның 10 нчы көнендә, Россия мөселман өммәте тормышында күптән көтеп алынган вакыйга булды – Махачкала шәһәренең Дуслык йортында ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан әзерләнгән «Калям Шариф. Перевод смыслов» басмасы рәсми рәвештә киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең чыгышында мәгънәви тәрҗемәне әзерләү үзенчәлекләренә тукталды, эш барышында юлыккан төп каршылыкларга игътибарны юнәлтте.

***

Татарстан мөфтие Мамадыш районының Дегетле авылында урнашкан 17 нче колония-поселениедә булды. Камил хәзрәт Сәмигуллинның әлеге сәфәре күркәм вакыйга белән башланып китте: төзәтү учреждениесендә дин кардәшләребез зарыгып көткән һәм тиз арада үз көчләре белән төзелгән мөселман гыйбадәтханәсе – агач мәчет ачылды. Әлеге мәчет биредә җәза үтүче 40 кеше өчен исәпләнгән, биредә шулай ук барлык уңайлыклары булган тәһарәтханә дә булдырылган.

Әлеге чараны Татарстан мөфтие Коръән укып һәм дога кылып башлап җибәрде, яңа мәчеткә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсел шәҗәрәсе язылган шәмаил бүләк итте.

***

ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә мөселман һөнәри дини белем бирү оешмалары (мәдрәсәләр) җитәкчеләренең чираттагы җыелышы узды. Киңәшмәдә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, шулай ук ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты вәкилләре катнашты. Көн тәртибендә мәдрәсәләр эшчәнлеген федераль законнар нигезендә гамәлгә ашыру мәсьәләләре каралды.

## Чаллы яңалыклары

“Ихлас” мәчетендә Мәүлид аена багышланган мәҗлес булып узды. Чара кунагы итеп шәһәребез имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин чакырылган иде. Мәҗлес барышында “Ихлас” мәчете тормышында актив эш алып барган картларны тәбрикләделәр.

Шул ук көнне кичке намаздан соң ГЭС бистәсендә урнашкан “Каир” банкетлар залында “Фарыздыр киемең, мөслимә” исемле чара уздырылды. Әлеге чарада “Habibi” мөслимәләр өчен кием кибете Чаллы мөслимәләре берләшмәсе һәм мөхтәсибәт белән берлектә мөселман хатын-кызлары өчен күлмәкләр күргәзмәсе оештырды.

***

7 декабрьдә Чаллының “Ак мәчет” мәдрәсәсендә «Татар халкының рухи традицияләрендә нәсел тамырлары һәм төбәк тарихы” исемле II Россиякүләм фәнни-гамәли семинар узды. Бу семинар эшен алып баруда 10 фән докторы, профессорлар, 9 фән кандидаты, фәнни-тикшеренү институтларының фәнни хезмәткәрләре, мәдрәсә мөгаллимнәре катнашты. (Тулырак язма газетаның 3 нче битендә)



***

Чаллыда Инвалидлар декадасына багышланган ярдәм ярминкәсе узды. Ярминкәдә мәктәп укучылары сату итте. Җыелган акча Мөхәмәдова Мәрьям исемле тумыштан инвалид кызга тәгаенланды. Катнашкан балаларга, әти-әниләренә, ярминкәне оештыруда ярдәм иткән укытучыларга Аллаһының рәхмәтләре булсын. Мәрьямнең әнисе һәм үзе әлегә ярдәмгә бик рәхмәтле.

## “Хәлең ничек, мәхәллә?”



25 ноябрь көнне Чаллының “Хәләл үзәк” сәүдә йортында мәчет хезмәткәрләре өчен “Хәлең ничек, мәхәллә?” дип аталган мәҗлес булып үтте. Аны “ГЭС мәхәлләсе” мәчете имам-хатыйбы Габдерәшит хәзрәт Коръән укып һәм “Утыз Имәни” мәчете имам-хатыйбы Салихҗан хәзрәт дога кылып башлап җибәрделәр. Әлеге чарага шулай ук “Минем Пәйгамбәрем” исемле видеороликлар һәм “Пәйгамбәрем шәҗәрәсе” дип аталган рәсемнәр конкурсларында катнашучылар да чакырылганнар иде. Чараның беренче өлешендә шушы бәйгеләрдә җиңүчеләрне бүләкләү булды. “Пәйгамбәрем шәҗәрәсе” конкурсында җиңүчеләр: Әхмәтшин Йосыф, Усманова Розалия, Ногманова Эльвина. Иң сәнгатьле эш – Шәрипова Сөембикә.Үзенчәлекле һәм заманча итеп эшләнгән эшләр: Мосифулин Нурислам, Әүхәдиева Мәликә, Әхмәтшина Һаҗәр, Фатыйхов Нурислам, Яруллина Ясминә, Сәмигуллин Алмаз.

“Минем Пәйгамбәрем” видеороликлар конкурсында җиңүчеләр: “Утыз Имәни” мәхәлләсе, «Нур-Ихлас» мәчете шәкертләре, Ногмановлар гаиләсе.

Конкурсларда катнашкан, ләкин беренчелекне яулый алмаган кешеләр дә бүләксез калмады. Аларның барысына да “Хәләл үзәк” директоры тарафыннан әзерләнгән бүләкләр тапшырылды.

Мәҗлеснең икенче яртысында мәчетләр эшчәнлеге турында фикер алышу булды. Аның барышында мәчет кизүләренә аерым кием, мәчетләрдә кирәкле сорауларга тиз җавап табып булган кечкенә китапханәләр, килгән халык белән сөйләшу скриптлары кертергә кирәк дигән тәкъдимнәр әйтелде. Шәһәребез имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин дини сораулар белән килгән кешеләрне мәчет имамнарына җибәрергә кушты. Шулай ук “Чишмә” һәм “Ихлас” мәчетләре имамнары җыелган халыкны үзләренең еллык эш нәтиҗәләре белән таныштырды.

Чара дәвамында катнашучылар тәмле пылау һәм чәй белән сыйландылар. Мәҗлесне Әлфәс хәзрәт чарада катнашкан мәчет хезмәткәрләренә рәхмәтләрен белдереп тәмамлады. Киләчәктә дә бер-беребез белән киңәшләшеп эш алып барырга кирәк дигән теләктә калды.

**Нияз ГАЗИЗОВ.**

# Башка милләт һәм дин кешеләренә хөрмәт

Барча мактаулар, хәмде-сәналар Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә. Аның хак хәбибе, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә дә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгаләнең безне төрле милләт, дин вәкилләре итеп яратуының хикмәте бар. Боларны аңлаган ихлас мөселман кешесе беркайчан да башка милләт, дин кешеләренә начар мөгамәләдә булмый.

Кешеләрнең үзара дус-тату яшәүләренең мөһимлеге хакында Коръәни Кәримнең күп аятьләре бәян итә: «Ий мөэминнәр, бер кавем икенче бер кавемне кимсетмәсен, ул кимсетелгән кавемнең кимсетә торган кавемнән яхшырак булуы ихтималдыр, шулай ук хатыннар икенче хатыннарны кимсетмәсеннәр, кимсетелгән хатын кимсетүче хатыннан яхшырак булуы ихтималдыр, вә дин кардәшләрегезне гаепләп кимсетмәгез, вә бер-берегезгә яман исемнәр илә дәшмәгез, мөэмин булганнан соң, фасыйк исеме ни яман исемдер. Бу эшне эшләүчеләр тәүбә итеп төзәлмәсәләр, алар залимнәрдер». («Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:11)

Аллаһы Тәгалә кешеләрне үзара ызгышып, талашып яшәсеннәр өчен яратмады. Ул адәм балаларының бер-берләрен рәнҗетеп, кан коеп яшәүләрен теләми. Кызганычка, кешеләр бер дә юктан тавыш чыгарып, уртак тел таба алмыйча, үзара талашып яши бирә. Үзләренең шәхси мәнфәгатьләрен, ихтыяҗларын кайгыртканнары аркасында башкаларның хокукларын бозучылар күп. Нәтиҗәдә, үзен генә хаклы дип яшәүчеләр башкалар белән конфликтлы хәлләргә тарый. Мондый очракларга мәсьәләне зурга җибәрмичә генә хәл итә белү яхшы, әлбәттә. Шуңа да бәхәсләр аркасында кешеләр арасында фетнә чыгудан сак булсак иде. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди: «Ий мөэминнәр, күп гөманнан (уй-фикерләрдән) сакланыгыз, тәхкыйк, бәгъзе (кайбер) гөманда гөнаһ бардыр. Вә кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, кеше гаебен эзләмәгез вә бәгъзегез бәгъзегезне гайбәт кылмасын! Әллә сезнең берәрегез үлгән кардәшенең итен ашауны сөярме? Сез, әлбәттә, аны мәкруһ күрдегез, гайбәт сөйләүне дә шулай мәкруһ күрегез! Аллаһыдан куркыгыз, гайбәт эшләреннән тәүбә итегез! Шиксез, Аллаһы тәүбә итеп төзәлгән кешеләрне гафу итүче вә рәхимледер». («Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:12)

Кызганычка, күпсанлы һәм көчлерәк халыклар икенчеләрне түбәнсетергә дә ярый, дип саныйлар. Кешедәге бу халәт аның нәфесе азганнан килә. Ул үзен башкалардан яхшырак, дип уйлый башлый. Мондый ялгышлык адашканлык аркасында, без барыбыз да Аллаһының мәхлуклары икәнен, һәрберебезнең дә җир йөзендә яшәргә хакыбыз барлыгын онытабыз, шуның белән гөнаһка төшәбез. Менә шушы гамәлләрдән сак булсак иде, мөхтәрәм дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгалә Коръәндә: «Җир өстендә зураеп күкрәк киереп йөрмә, чөнки син никадәр зурайсаң да җирне ертырга хәлеңнән килмәс һәм никадәр зурайсаң да таулар хәтле зурая алмассың!» - дип әйтә. («Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:37)

Үзара фетнәләр чыгу турында сүз кузгалткач, шайтанның да үз эшен башкаруын онытмасак иде. Ул безгә, тегеләр башка милләт, дин, этнос, раса кешесе, сез аларга караганда өстенрәк дип, пышылдап шик-шөбһә тудырып тора.

«Хәмер эчүегез һәм отыш уеннары уйнавыгыз белән, әлбәттә, шайтан арагызда дошманлыкны һәм бер-берегезгә һөҗүм иттерә торган ачуны булдырырга тели вә Коръән вәгазеннән, намаз укудан сезне тыярга тели, шулай булгач, ул шайтан эше булган - нәҗесләрдән тыеласызмы? Әллә тыелмыйсызмы? Әлбәттә тыелыгыз!» (“Маидә/ Аш яулыгы”, 5:91)

Тәкәбберлек, үзеңне башкалардан яхшырак дип санау аркасында кылынган гөнаһларның тәэсире башкаларга да күчә. Ягъни бу гөнаһы белән ул бүтәннәрне дә гөнаһка тарта. Иблис мәлгунь тәкәбберлеге белән Адәм галәйһиссәлам алдында сәҗдә кылмады, шул гамәле белән Аллаһының ачуына төште, адәм затына дошман булды. Әле моның белән генә бетми, ул Аллаһы Тәгаләнең Адәм галәйһиссәламне зурлаганына, аны яратканына ачуы килеп, хөсетлек илә атабыз Адәм галәйһиссәлам белән анабыз Хәвва радыяллаһу ганһәне ялгыш юлдан яздырырга план кора. Ялган һәм мәкер юлы белән Аллаһы Тәгаләнең тыйган җимешен ашата.

Фикерләүчеләр өчен бу кыйссада гыйбрәтле дәрес һәм нәсыйхәт бар. Эзлеклелек буенча карасак, күп кенә гөнаһларның башында тәкәбберлек, көнчелек һәм үч ята. Шушы начар сыйфатлар белән чолганып алган кеше башкаларга зыян сала, Аллаһы Тәгаләнең тыйганнарыннан тыелмыйча, гөнаһка керә. Моның белән үзен дә, башкаларны да һәлакәткә алып бара. адәм баласы бары бер гамәле белән генә үзен Аллаһының ачуыннан саклап калырга мөмкин: ул - ихластан хатаңны танып, тәүбәгә килү. Шул рәвешле, атабыз Адәм галәйһиссәлам дә вакытында үзенең гаебен танып, Аллаһыдан гафу сорый, һәм мәрхәмәтенә, гафу итүенә лаек була. Һичшиксез, Аллаһы Тәгалә гаепләрен танып, гафу сораучыларны кичерә. Моның турында Ул Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: «Тәүбә итеп, иман китергән вә Коръән юлы белән изге гамәлләр кылган, соңра туры юлга күнелеп, үлгәнче хак юлда таза торган кешеләрне Мин, әлбәттә, ярлыкаучымын». («Та Һа», 20:82)

Аңлавыбызча, бүгенге көн проблемаларының нигезендә берәүләрнең үзләрен икенчеләрдән яхшырак дип тоюы, тәкәбберләнү, көнләшү кебек сыйфатлар ята. Тәкәбберлек, үз чиратында көчлерәкләрнең көчсезләрне түбәнсетүенә, хокукларын бозуга китерә. Тарихка күз салсак, сугышлар, конфликтлар ике якның уртак тел таба алмаулары, юл куя белмәүләре аркасында килеп чыкты. Ә үзләрен башкалардан өстенрәк дип күрүчеләр, һәрвакыт хаклы дип уйлаучылар беркайчан да юл куя белми, башкалар белән дус-тату мөнәсәбәттә яшәргә омтылмый. Тәкәббер кешеләрнең үзләренә дә җиңел түгел, чөнки тәкәбберлек дигән «корт» кешене эчтән кимерә, аның бу дөньясын да агулый, теге дөнья бәхетеннән дә мәхрүм итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тузан бөртеге кадәрле генә тәкәбберлеге булса да, ул кеше җәннәткә керми», - дип әйткән.

«Ий кешеләр, Без сезләрне ир вә хатын итеп халык кылдык, вә сездән тармаклар вә кабиләләр кылдык бер-берегезне таныр өчен, тәхкыйк сезнең Аллаһы хозурында хөрмәтлерәгегез - Аллаһыдан куркып, гөнаһлардан сакланучыгыздыр, Аллаһы белүче вә һәр эшегездән хәбәрдар». («Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:13)

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Бу аятьтән күренгәнчә, без барыбыз да Аллаһы Тәгалә каршында тигез. Беребезнең дә башкаларны хурлап, кимсетеп яшәргә хакыбыз юк. Аллаһы Тәгалә байлыгыбызга, дәрәҗәбезгә, матурлыгыбызга түгел, ә тәкъвалыгыбызга карый. Аның алдында иң хөрмәтлебез дә гөнаһлардан ерак булганыбыз, Аллаһыдан куркып, тыйганнарыннан тыелып, кушканнарын үтәп яшәргә тырышучыбыз.

Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә тынычлык, иминлек биреп, белгәннәребез белән гамәл кылырга, ишеткәннәребез белән вәгазьләнергә һәм булган кимчелекләребезне бетереп, камиллеккә ирешергә насыйп итсә иде.

**Тимергали хәзрәт Юлдашев,**
**Казанның «Сәлах» мәчете**
**имам-хатыйбы.**

# Чын мөэминнәр

Бервакыт Гали (радыйәллаһү гәнһү) Мөхәммәд пәйгамбәрнең күңел халәте турында сорагач, ул (с.г.в.с.) болай дип җавап биргән:

- Минем малым ул – дөрес аңлау, динемнең нигезе – акыл, төпле терәгем–

мәхәббәт, хәрәкәт итү чарасы – теләк, даими юлдашым – Аллаһны искә алу, байлыгым – ышанычлылык, дусларым – проблемалар һәм кайгы, коралым – гыйлем, киемем – сабырлык, ганимәтем (трофей) – канәгатьлек, горурлыгым – тыйнаклык, һөнәрем – ләззәтләрдән читләшү, максатым – хаклык, дөреслек, дан-шөһрәтем – буйсыну, тормыш рәвешем – көрәш, күз нурым – намаз.

Бервакыт Мөхәммәд пәйгамбәр (с..г.в.с.) сәхабәләренә мөрәҗәгать итеп: “Сез бүген нинди халәттә?” – дип сораган. Сәхабәләр: “Без гадәттәгечә Аллаһка иман китергән халәттәдер”, – дип җавап бирделәр. Шуннан соң пәйгамбәребез (с.г.в.с.): “Ә иманыгызның күрсәткече нинди?” – дип сорагач, алар болай җавап бирделәр:

- Авырлык, кайгы, бәхетсезлек вакытында без Аллаһ ризалыгы өчен сабыр итәбез, исән-имин хәлдә уңышка ирешсәк, барысы да тыныч, яхшы булса, Аллаһыга шөкер итәбез, һәм Аллаһы Тәгалә безгә тәкъдирләгән нәрсәләрдән гел разый, канәгать булуыбызны белдерәбез.

Моны ишетүгә пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.с.) шатланып әйтте:

- Аллаһ белән ант итәм: сез – чын мөэминнәр.

**Ришат Курамшин әзерләде.**

# Колак салсаң, үкенмәссең

** Әгәр кешенең күңелендә бер тамчы булса да тәкәбберлек бар икән, шул җәннәткә кермәс*

** Аллаһы Тәгалә сезнең йөзләрегезнең матурлыгына, киемнәрегезгә һәм малларыгызга карамас, бәлки калебләрегезгә карар*

** Кыямәт көнендә Аллаһ Тәгалә өч кеше белән сөйләшми, аларның гөнаһларын гафу итми һәм аларга таба карамый да. Аларга авырттыручы бик ачы газап була. Алар - зина кылучы карт бабай, халкын алдалаучы ялганчы патша һәм тәкәббер фәкыйрь*

** Тәкәбберлек – ул хакны кабул итмәү һәм кешеләрне кимсетү*

** Раббым Аллаһ, мин сиңа ялкаулыктан, тәкәбберлек сыйфатыннан, җәһәннәм утыннан һәм кабер газабыннан саклауны сорап сыенам*

** Түбәң күккә тисә дә, аягың җирдә булыр*

**Югарыга карап үрнәк ал, түбәнгә карап гыйбрәт ал*

# Кыямәт көненең галәмәтләре

*(Дәвамы. Башы газетаның алдагы саннарында)*

Булган һәм кабатланып тора торган галәмәтләр.

8. Нindидер эшне аны эшләргә лаек булмаган кешеләргә тапшыру.

Пәйгамбәребездән (с.г.в.) сорадылар: “Йә рәсүлуллаһ! Кыямәт көне кайчан була?”. Ул (с.г.в.) әйтте: “Әгәр кешеләр арасында әманәт (сүздә тору) югалса, Кыямәт көнен көтегез”. Аннан соң сорадылар: “Әманәтнең югалуы ничек була?” Пәйгамбәребез әйтте: “Әгәр берәр эш лаеклы булмаган кешегә хаксыз рәвештә тапшырылса, шул әманәт югалу буладыр”. (Мондый кешеләрдә җаваплылык хисе булмый, ул башка кешеләрне кайгыртмый һәм сүзендә тормый).

9. Сәүдә эшләренең артык җәелеп, күбәеп китүе; сәлам биргәндә үз танышыңа гына сәлам бирү; туганнар арасындагы бәйләнешләрнең, аралашуның өзелүе.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Кыямәт көне алдыннан кешеләр белгән кешеләренә генә сәлам бирер, сәүдә эшләре киңәер һәм хатын-кызлар ирләренә сәүдә итәргә булышыр”.

10. Ялган сүзне кабул итү, хаклыкны кабул итмәү.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Кыямәт көне алдыннан ялган шәһадәт бирү һәм хак сүзне яшерү таралыр”.

11. Фәкыйрь кешеләр баеп китеп, йорт төзеп үзара ярышыр; кол хатын үзенең хуҗасын тудырыр.

Хәдиснең икенче яртысына аңлатма: ата-аналарның балаларын узындырып, бөтен көйсезлекләрен үтәве; ата-анага хөрмәт югалу һәм балаларның аларны хезмәтче, кол итеп күрүе; никахсыз туган бала ятимнәр йортында үсә, соңыннан ул бала үсеп җитеп, югары дәрәҗәгә күтәрелә һәм үз анасы аны белмичә, танымыйча аңа хезмәт итә.

(“Ислам дине нигезләре”ннән. Дәвамы бар)

## “Ак мәчет”тә файдалы семинар

Чаллы шәһәренең “Ак мәчет”мәдрәсәсендә ислам динен пропагандалаудан тыш, халкыбызның милли аңын үстерүгә багышланган чаралар да еш үткәрелә.Узган ел нәсел шәҗәрәләрен төзү-өйрәнүгә багышланган төбәкара конференция катнашучыларда зур кызыксыну уятканлыктан, быел аның статусын күтәреп, Рәсәйкүләм фәнни-гамәли семинар үткәрергә булдылар. “Татар халкының рухи традицияләрендә нәсел тамырлары һәм төбәк тарихы” дип исемләнгән бу чара 7 декабрь көнне мәчет бинасында үтте. Корьән аятьләре, Кама буе төбәге казые, “Ак мәчет”нең имам-хатыйбы, мәдрәсә директоры Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиевның кереш сүзе һәм шәһәребезнең имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллинның фатихасы белән актлар залында башланып киткән семинарның пленар утырышында Казаннан килгән күренекле галимнәр - филология фәннәре докторы, профессор, академик М.Х. Бакиров, филология фәннәре докторы, профессор, халыкара “Тюркологик тикшеренүләр”журналының баш редакторы Ф.С. Хәкимҗанов, тарих фәннәре докторы, Казан федераль университеты профессоры Г.М. Дәүләтшин халкыбызның тарихы һәм рухи традицияләре турында тирән эчтәлекле докладларын укыды.

Өйлә намазыннан соң, семинар үз эшен өч секциягә бүленеп дәвам итте. Чыгыш ясаучылар арасында Казанннан, республикабыз районнарыннан, Башкортостаннан, Киров өлкәсеннән килгән мәдрәсә мөгаллимнәре, имам-хатыйплар, Чаллы дәүләт педагогика университеты укытучылары һәм студентлары, “Ак мәчет” мәдрәсәсе мөгаллимнәре һәм шәкертләре бар иде. Барлык чыгышлар да зур игътибар һәм кызыксыну белән тыңланды. Тәнәфес вакытларында кунаклар мәдрәсәдә оештырылган”Татар ислам мәгарифе” музее белән дә таныштылар.

Йомгаклау утырышында Рөстәм хәзрәт, педуниверситет доценты Р.И. Хаҗиев һәм секция җитәкчеләре семинарда укып-тикшерелгән докладларга анализ ясады. Кунаклар һәм катнашучылар, семинарның бик югары дәрәҗәдә оештырылуын билгеләп, “Ак мәчет” җитәкчелегенә рәхмәтләрен җиткерде, бу чара традициягә әйләнеп, ел саен үткәрелсен иде дигән теләкләрен белдерде, семинар материалларын аерым китапка туплап чыгару хәбәрен шатланып кабул итте.

**Рәиф Закиров, филология фәннәре кандидаты, доцент.**

## ӘДӘБИ СҮЗ

*Рифат СӘЛАХ*

### Пәйгамбәргә

*Хакыйкатькә һәрчак каршы гавам,*
*Хакыйкатькә куеп авызлык*
*Күп кешеләр яшәмәкче була,*
*Эстән ләззәт, кылып явызлык.*
*Үз-үзләрен илаһ итеп тоеп*
*Яшәп яткан чакта адәмнәр,*
*Син тугансың, газиз Рәсүлуллаһ,*
*Аллаһыдан килгән пәйгамбәр.*
*Үз кавемең синә Әмин дигән,*
*Аннан мәҗнүн диеп атаган...*
*Дошмандыр шул, итагатьле булып,*
*Куркып яшәүчеләр Алладан.*
*“Үтерергә!” – дигән Иблис үзе,*
*Кылыч биргән кырык егеткә.*
*Аллаһ кушса,*
*Синә зыян тими,*
*Дошманнарың сине күреп тә.*
*Син җиңгәнсең!*
*Кылыч белән түгел,*
*Хакыйкать һәм тугры дин белән.*
*...Исемеңне искә алган саен*
*Күз яшьләре чыга... күңелдән.*

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

# Һидаять турында

***Дога кылганда, әбиләрнең: «Аллаһы Тәгалә һидаятьне насыйп итсә иде, шул юлда булсак иде», – дип сораганнарын ишеткәнебез бар. Шәригатьтә «һидаять» сүзе нәрсәне аңлата, аңа ирешү өчен нәрсә эшләргә кирәк? «Казан нуры» мәчете имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт МӨХЛИСОВтан шуңа аңлатма бирүен үтендек.***

– Һидаять «туры юлга керү», «дөрес юлдан бару» дигән мәгънәне аңлата. Аллаһның барлыгына һәм берлегенә ышанып, Аның кушканнарын үтәп яшәү ул. Туры юл дигәннән, элек коммунистлар вакытында аны Ленин сызган юл дип әйтә иделәр. Һәр партия, җәмгыять, оешманың үз юлы бар. Әмма барыбыз да Аллаһ кушкан юлдан барырга тиешбез. «Фатиха» сүрәсендә «Иһдинәс-сыйраатальмүстәкыйиим» дигән юллар бар. Тәрҗемәсе: «Йа Аллаһ, безне туры юлдан алып барсаң иде». Намаз укыган кеше бу җөмләне көненә 32 тапкыр һәр рәкәгатьтә әйтә. Димәк, Алла кушканча яшәсә дә, намаз укыса да, ул көн дә Аллаһтан туры юлга күндерүен сорый булып чыга. Диндә булган кешенең, Алла сакласын, ялгыш юлга кереп китүе дә бар. Безгә һидаятьне бары Аллаһы Тәгалә генә бирә. Пәйгамбәрләр, сәхабәләр халыкны дингә өндәгән, әмма туры юлга Аллаһ кына кертә.

***– Намаз укымаучылар: “Аллаһы Тәгаләдән вакыты җитмәгән, әле күңелгә салмаган”, - дип аклана...***

– Ул – кешенең үз-үзен тынычландыруы гына. Гайбәт сатучылар кешене сөйләп туялар да, гыйбрәт өчен сөйләштек, дигән булалар. Намаз укымаучы вакыты юклыкка, хәтере начар булуга сылтый. Намазны бәлигълык яшенә җиткән бөтен кеше дә укырга тиеш. Ул – Аллаһ кушкан фарыз гамәл. Укымасаң – гөнаһ. Гайбәт сөйләүнең дә гөнаһы Аллаһ каршында бик зур.

***– Туры юлга баса алмаган кеше турында, шайтаны котырта, дип тә әйтәләр. Монда кем гаепле?***

– Шайтаннан саклану өчен, Аллаһының әмерләрен үтәргә һәм хәрәмнән тыелырга кирәк. Кеше кыш көне өстенә кимичә урамга чыга да салкын тидерә, чөнки ул сакланмады. Без дә гел гыйбадәттә булып, догалар кылып, дин кушканча яшәсәк, шайтан зыян сала алмаячак. Ул, кешенең алдына да, артына да төшәрмен, уңнан да, сулдан да килермен, ничек тә адәм баласын котыртып, үзем белән җәһәннәмгә алып китәрмен, дигән. Тәнебезне генә түгел, күңелебезне дә сакларга тиешбез. Күңелне – җанны ничек сакларга кирәклеген Аллаһы Тәгалә безгә аңларлык итеп әйткән. Диндәге таләпләрне үтәп яшәсәк, күңелне генә түгел, тәнебезне дә саклый алабыз. Шайтан котыртты дип, аңа сылтап калдыру җайлырак бит. Үзгәрергә теләмәсәң, кеше-шайтанга әвереләсең дә куясың. Ә алар безнең арада бар. Мәчеткә барырга уйлаган кешене, анда синә нәрсә калган, йөрмә бабайлар кебек, дип, юлыннан бүлгән кеше шайтан булмый кем була. Коръәннең «Нәс» сүрәсе дә бит «Минәл-җиннәти вән-нәәс» дип тәмамлана, ягъни җеннәрдән һәм адәмнәрдән сакла. Диндә булу алай ук җиңел эйбер түгел, нәфесеңне белән көрәшү ул. Ихтыяр көчеңне беразгына югалтып алсаң да, шайтан хәзер сизеп ала. Аракы эчә торган кешегә ул, исерерсең дә бомж кебек урамда аунап ятарсың, эшсез дә, гаиләсез дә калырсың, дими. Киресенчә, бүген генә эчкәннән әллә ни булмас, табиблар да аз гына эчеп куярга киңәш итә, кебек сүзләр белән котырта гына. Аллаһы Тәгалә Коръәндә Иблиснең сүзләрен китереп шулай ди: «Ул әйтте: «Синең кодрәтең белән ант итәмен ки, мин аларның бөтенесен дә, гөнаһлар кылдырып, туры юлдан чыгарачакмын. Иллә дә мәгәр, Син сайлап алган колларыңны гына туры юлдан чыгара алмаячакмын».

Шайтаннан саклану өчен диндә булырга, гел тәһарәтле йөрергә, бөтен эшне дә Аллаһка тәвәккәлләргә кирәк. Иртән эшкә киткәндә, Аллага тапшырдым дип чыгып китәбез, кайтып кергәндә, ишектән бисмилла әйтеп керергә онытабыз. Мөхәммәд галәйһиссәлам, әгәр кеше ишектән кергәндә Аллаһны искә алырга онытса, безгә кереп кунарга урын булды дип, аңа шайтан да ияреп керер, ашарга утырганда бисмилла әйтмәсә, шайтан, миңа ашарга да бар икән, дип килеп утырыр, ди. Аннары без адәм балалары Аллаһны үзебезгә авыр вакытларда гына искә алабыз. Мәчеткә, мине өшкерегез әле, дип килүчеләр бик күп. Намаз да укыйсылары, мәчеткә дә йөриселәре килми үзләренең. Проблема чыга да мәчетне искә төшерәләр. Якыннары үлеп китә дә, хәзрәтне чакыралар, дога кылдыралар. Мәетнең өчесе, җидесе, кырыгына чакыралар. Сәдака бирдем, укыттым диләр дә җиңел сулап куялар. Кулларын күтәреп, вафат булган якыны өчен дога кылса, намаздан соң Аллаһы Тәгаләдән аңа җиңеллек сораса иде ул. Үзләренең Аллаһ коллары булуларын, Аның каршында җавап бирәчәгебезне онытмасалар иде. Иманны, тәкъвалыкны сатып алып булмый шул.

***– Бәхетсезлек очракларына юлыкканда, авырулардан соң кайберәүләр намазга баса. Бу Аллаһның теләге белән шулай килеп чыгамы?***

– Берәр бәла-казага юлыксак, чынлап та күбрәк дога кыла, Аллаһтан сорый башлыйбыз. Уразасын да тотабыз. Әмма проблема хәл ителгәч, сәламәтләнгәч, тагын онытып җибәрәбез. Самолетка утырганда куркудан, догаларны укыйбыз, ә җиргә төшкәч, кул чабабыз да диңгезгә йөгерәбез. Кире кайтырга чыккач, исән-сау кайтып җитсәк иде, дип, тагын Аллаһтан сорый башлыйбыз. Операциягә керергә җыенган кеше үзе дә, туганнары да килә мәчеткә. Дога кылдыралар, намазга да басарга әзер булып китәләр инде менә. Наркоздан айныгач, операцияне яхшы табиб ясады, әйбәт дәвaладылар дип сөенәләр. Табибка, бәхилләтер өчен, кучтәнәчен дә бирәбез. Ә менә Аллаһка рәхмәт әйтеп, ике рәкәгать шөкер намазын укырга иренәбез. Аның каршындагы бурычларны үтәмибез. Югыйсә табибка да сәләтне, мөмкинлекне, белемне Аллаһы Тәгалә бирә бит. Сессия вакыты җиткәч, студентлар да, аларның эти-әниләре дә искә төшерә безне. Мәчеттә дога кылдырырга кайчак хәтта чират җыела. Аллага шөкер, имтиханны бишлегә бирдем дип, дога кылдырган кешене хәтерләмим.

Йокыдан уянабыз да, сикереп торып, моңа-тегеңә өлгерәсе бар дип сукрана-сукрана чаба башлыйбыз. Йокыдан исән-сау уяна алган өчен рәхмәт әйтергә онытабыз. Кем белә бит кемнең кайчан уяна алмаячагын? Раббыбызны онытсак, Ул Үзе турында искә төшертергә дә бик мөмкин. Дингә дә төрле кешене төрлечә китертә. Кемдер авырлык килгәч, аны аңлап, туры юлга баса. Ә кемдер барыбер аңламаска да мөмкин. Тәүбә итсә, Аллаһы Тәгалә аны кабул итә. Бер, ике, өч тапкыр гафу итә. Ә гафу итмәсә? Башта Ул кечерәк авырлык бирә, аннары аннан авырраган, аннары инде тагын да зур авырлык килергә мөмкин.

***– Авыр вакытта нәзер әйтергә яратабыз. Авыру кеше: «Сәламәтләнсәм, намазга басар идем», – дип нәзер әйтеп куярга мөмкин. Кемдер бу нәзере турында оныта да. Аның гөнаһы зурмы?***

– Кеше болай да намаз укырга тиеш. Әгәр намазларын укып бармаса, аңа гөнаһ язылып бара. Бу очракта исә икеләтә гөнаһ була. Нәзере турында Аллаһы Тәгалә бу дөньяда яки кыямәт көнендә искә төшерәчәк. Ахирәткә калдырмыйча, бу дөньяда ук сиздерсә ярый ла ул. Барысы да рәхәт кенә, шома гына барса да куркыныч бит. Дөньядагысын ничек тә үткәреп була, ахирәткә калса куркыныч. Ибраһим галәйһиссәлам дә Аллаһы Тәгаләдән, әгәр миңа угыл бирсәң, мин аны корбан итеп чалырга әзер, дигән булган. Әмма Аллаһы Тәгалә, әйткән нәзеренә тугры булуын күргәч, корбан итеп улын түгел, куй чалырга куша. Нәзер әйтелгән икән, ул үтәлергә тиеш.

**Әңгәмәдәш - Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА (“Шәһри Казан”).**

# Намаз вакытлары

| Милади Гыйнвар | Көн исеме | Җөм.-әувәл, Җөм.-ахир | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Таң беленә Чаллы | Таң беленә Казан | Мәчетләрдә укыла Уфа | Мәчетләрдә укыла Чаллы | Мәчетләрдә укыла Казан | Кояш чыга Уфа | Кояш чыга Чаллы | Кояш чыга Казан | Зәвәл Уфа | Зәвәл Чаллы | Зәвәл Казан | Өйлә Уфа | Өйлә Чаллы | Өйлә Казан | Икенде Уфа | Икенде Чаллы | Икенде Казан | Ахшам Уфа | Ахшам Чаллы | Ахшам Казан | Ясту Уфа | Ясту Чаллы | Ясту Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Чш | 6 | 07:23 | 05:40 | 05:53 | 08:09 | 06:29 | 06:43 | 09:39 | 07:59 | 08:13 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:45 | 13:20 | 13:33 | 16:59 | 15:07 | 15:20 | 18:53 | 17:05 | 17:18 |
| 2 | Пж | 7 | 07:23 | 05:40 | 05:53 | 08:09 | 06:29 | 06:42 | 09:39 | 07:59 | 08:12 | 13:19 | 11:34 | 11:47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:46 | 13:21 | 13:34 | 17:00 | 15:08 | 15:21 | 18:54 | 17:06 | 17:19 |
| 3 | Җм | 8 | 07:23 | 05:39 | 05:53 | 08:08 | 06:29 | 06:42 | 09:38 | 07:59 | 08:12 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:47 | 13:22 | 13:35 | 17:02 | 15:10 | 15:23 | 18:55 | 17:07 | 17:20 |
| 4 | Шм | 9 | 07:23 | 05:39 | 05:53 | 08:08 | 06:28 | 06:42 | 09:38 | 07:58 | 08:12 | 13:20 | 11:35 | 11:48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:48 | 13:23 | 13:36 | 17:03 | 15:11 | 15:24 | 18:56 | 17:08 | 17:21 |
| 5 | Як | 10 | 07:23 | 05:39 | 05:52 | 08:08 | 06:28 | 06:41 | 09:38 | 07:58 | 08:11 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:49 | 13:25 | 13:38 | 17:04 | 15:12 | 15:25 | 18:57 | 17:09 | 17:22 |
| 6 | Дш | 11 | 07:23 | 05:39 | 05:52 | 08:07 | 06:27 | 06:41 | 09:37 | 07:57 | 08:11 | 13:21 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:50 | 13:26 | 13:39 | 17:06 | 15:14 | 15:27 | 18:58 | 17:10 | 17:23 |
| 7 | Сш | 12 | 07:23 | 05:39 | 05:52 | 08:07 | 06:27 | 06:40 | 09:37 | 07:57 | 08:10 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:52 | 13:27 | 13:40 | 17:07 | 15:15 | 15:28 | 18:59 | 17:11 | 17:24 |
| 8 | Чш | 13 | 07:23 | 05:38 | 05:52 | 08:06 | 06:26 | 06:40 | 09:36 | 07:56 | 08:10 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:53 | 13:29 | 13:42 | 17:08 | 15:17 | 15:30 | 19:01 | 17:12 | 17:26 |
| 9 | Пж | 14 | 07:22 | 05:38 | 05:51 | 08:05 | 06:26 | 06:39 | 09:35 | 07:56 | 08:09 | 13:23 | 11:37 | 11:50 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:54 | 13:30 | 13:43 | 17:10 | 15:18 | 15:31 | 19:02 | 17:14 | 17:27 |
| 10 | Җм | 15 | 07:22 | 05:38 | 05:51 | 08:05 | 06:25 | 06:38 | 09:35 | 07:55 | 08:08 | 13:23 | 11:37 | 11:50 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:55 | 13:32 | 13:45 | 17:11 | 15:20 | 15:33 | 19:03 | 17:15 | 17:28 |
| 11 | Шм | 16 | 07:21 | 05:37 | 05:50 | 08:04 | 06:24 | 06:37 | 09:34 | 07:54 | 08:07 | 13:23 | 11:38 | 11:51 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:57 | 13:33 | 13:46 | 17:13 | 15:21 | 15:34 | 19:04 | 17:16 | 17:29 |
| 12 | Як | 17 | 07:21 | 05:37 | 05:50 | 08:03 | 06:23 | 06:36 | 09:33 | 07:53 | 08:06 | 13:24 | 11:38 | 11:51 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:58 | 13:35 | 13:48 | 17:15 | 15:23 | 15:36 | 19:06 | 17:18 | 17:31 |
| 13 | Дш | 18 | 07:20 | 05:36 | 05:49 | 08:02 | 06:22 | 06:36 | 09:32 | 07:52 | 08:06 | 13:24 | 11:38 | 11:51 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 14:59 | 13:36 | 13:49 | 17:16 | 15:25 | 15:38 | 19:07 | 17:19 | 17:32 |
| 14 | Сш | 19 | 07:20 | 05:35 | 05:49 | 08:01 | 06:21 | 06:35 | 09:31 | 07:51 | 08:05 | 13:25 | 11:39 | 11:52 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:01 | 13:38 | 13:51 | 17:18 | 15:27 | 15:40 | 19:08 | 17:20 | 17:34 |
| 15 | Чш | 20 | 07:19 | 05:35 | 05:48 | 08:00 | 06:20 | 06:33 | 09:30 | 07:50 | 08:03 | 13:25 | 11:39 | 11:52 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:02 | 13:40 | 13:52 | 17:20 | 15:28 | 15:41 | 19:10 | 17:22 | 17:35 |
| 16 | Пж | 21 | 07:18 | 05:34 | 05:47 | 07:59 | 06:19 | 06:32 | 09:29 | 07:49 | 08:02 | 13:25 | 11:40 | 11:53 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:03 | 13:41 | 13:54 | 17:21 | 15:30 | 15:43 | 19:11 | 17:23 | 17:36 |
| 17 | Җм | 22 | 07:18 | 05:33 | 05:46 | 07:58 | 06:18 | 06:31 | 09:28 | 07:48 | 08:01 | 13:26 | 11:40 | 11:53 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:05 | 13:43 | 13:56 | 17:23 | 15:32 | 15:45 | 19:13 | 17:25 | 17:38 |
| 18 | Шм | 23 | 07:17 | 05:33 | 05:46 | 07:57 | 06:17 | 06:30 | 09:27 | 07:47 | 08:00 | 13:26 | 11:40 | 11:53 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:06 | 13:45 | 13:58 | 17:25 | 15:34 | 15:47 | 19:14 | 17:26 | 17:39 |
| 19 | Як | 24 | 07:16 | 05:32 | 05:45 | 07:56 | 06:15 | 06:29 | 09:26 | 07:45 | 07:59 | 13:26 | 11:41 | 11:54 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:08 | 13:46 | 13:59 | 17:27 | 15:36 | 15:49 | 19:16 | 17:28 | 17:41 |
| 20 | Дш | 25 | 07:15 | 05:31 | 05:44 | 07:55 | 06:14 | 06:27 | 09:25 | 07:44 | 07:57 | 13:27 | 11:41 | 11:54 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:09 | 13:48 | 14:01 | 17:29 | 15:38 | 15:51 | 19:17 | 17:30 | 17:43 |
| 21 | Сш | 26 | 07:14 | 05:30 | 05:43 | 07:54 | 06:13 | 06:26 | 09:24 | 07:43 | 07:56 | 13:27 | 11:41 | 11:54 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:11 | 13:50 | 14:03 | 17:31 | 15:40 | 15:53 | 19:19 | 17:31 | 17:44 |
| 22 | Чш | 27 | 07:13 | 05:29 | 05:42 | 07:52 | 06:11 | 06:25 | 09:22 | 07:41 | 07:55 | 13:27 | 11:41 | 11:54 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:12 | 13:52 | 14:05 | 17:33 | 15:42 | 15:55 | 19:20 | 17:33 | 17:46 |
| 23 | Пж | 28 | 07:12 | 05:28 | 05:41 | 07:51 | 06:10 | 06:23 | 09:21 | 07:40 | 07:53 | 13:27 | 11:42 | 11:55 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:14 | 13:54 | 14:07 | 17:35 | 15:44 | 15:57 | 19:22 | 17:34 | 17:47 |
| 24 | Җм | 29 | 07:11 | 05:27 | 05:40 | 07:49 | 06:08 | 06:22 | 09:19 | 07:38 | 07:52 | 13:28 | 11:42 | 11:55 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:15 | 13:56 | 14:09 | 17:36 | 15:46 | 15:59 | 19:23 | 17:36 | 17:49 |
| 25 | Шм | 30 | 07:10 | 05:26 | 05:39 | 07:48 | 06:07 | 06:20 | 09:18 | 07:37 | 07:50 | 13:28 | 11:42 | 11:55 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:17 | 13:58 | 14:10 | 17:38 | 15:48 | 16:01 | 19:25 | 17:38 | 17:51 |
| 26 | Як | 1 | 07:09 | 05:24 | 05:37 | 07:46 | 06:05 | 06:18 | 09:16 | 07:35 | 07:48 | 13:28 | 11:42 | 11:55 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:18 | 13:59 | 14:12 | 17:40 | 15:50 | 16:03 | 19:27 | 17:39 | 17:52 |
| 27 | Дш | 2 | 07:08 | 05:23 | 05:36 | 07:45 | 06:04 | 06:17 | 09:15 | 07:34 | 07:47 | 13:28 | 11:43 | 11:56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:20 | 14:01 | 14:14 | 17:42 | 15:52 | 16:05 | 19:28 | 17:41 | 17:54 |
| 28 | Сш | 3 | 07:07 | 05:22 | 05:35 | 07:43 | 06:02 | 06:15 | 09:13 | 07:32 | 07:45 | 13:29 | 11:43 | 11:56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:21 | 14:03 | 14:16 | 17:44 | 15:54 | 16:07 | 19:30 | 17:43 | 17:56 |
| 29 | Чш | 4 | 07:06 | 05:20 | 05:34 | 07:42 | 06:00 | 06:13 | 09:12 | 07:30 | 07:43 | 13:29 | 11:43 | 11:56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:23 | 14:05 | 14:18 | 17:46 | 15:56 | 16:09 | 19:32 | 17:45 | 17:58 |
| 30 | Пж | 5 | 07:04 | 05:19 | 05:32 | 07:40 | 05:58 | 06:12 | 09:10 | 07:28 | 07:42 | 13:29 | 11:43 | 11:56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:25 | 14:07 | 14:20 | 17:48 | 15:58 | 16:11 | 19:33 | 17:46 | 17:59 |
| 31 | Җм | 6 | 07:03 | 05:18 | 05:31 | 07:38 | 05:57 | 06:10 | 09:08 | 07:27 | 07:40 | 13:29 | 11:43 | 11:56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15:26 | 14:09 | 14:22 | 17:51 | 16:01 | 16:14 | 19:35 | 17:48 | 18:01 |

*Балалар өчен*

## Минем бабай

Читек-кәвешләрен киеп,
Башка түбәтәен элеп,
– Әссәламүгаләйкум, – дип,
Сәлам бирә өйгә кереп.
Тыйнак кына үтә түргә,
Һәр кешегә башын иеп.
Кулларын өскә күтәрә:
– Өйгә дога кылыйк, – диеп.
Бәрәкәт теләп тормышка,
Дога кылыр өеп-өеп.
Куйган сыйны авыз итәр,
– Оҗмах нигъмәтләре, – диеп.
Бала-чагаңны онытмый,
Чыга хәер өлешләре.
Кесәсендә йөри аның
Конфет, өрек җимешләре.
Тәмле итеп сүзен сөйләр,
Моңлы итеп аять көйләр.
Ак сакаллы, ак күңелле
Бабам белән ямьле өйләр.

**Вәсимә ХӘЙРУЛЛИНА**

**Саулыгым – байлыгым**

## Сырганак



Сырганакның җимешләре дә, яфраклары да файдалы.. Сырганак яфрагыннан әзерләнгән чәй гипертониядән, пневмониядән, дерматиттан, шикәр авыруыннан, плеврит, атеросклероздан файдалы. Салкын тигән вакытта эчәргә була.Чәй 1 аш кашыгы кипкән сырганак яфрагына 1 литр кайнар су исәбеннән әзерләнә. Сырганакның мае да шифалы. Буыннар авыртканнан: эмаль кәстрүлдә ярты стакан сырганак маен җылытабыз да 1 аш кашыгы диңгез тозы белән 2 аш кашыгы бал өстибез. Болгатып бераз җылытып алабыз да, йоклар алдыннан авырткан буыннарга сөртәбез. Өстенә кәбестә яфрагы ябып, полиэтилен һәм йон тукыма белән каплыйбыз. Сырганакның мае авыртуны басу үзлекләренә ия; хатын-кыз авыруларын, пешүне, туңуны, тире чиләнүне, авыр төзәлә торган яраларны, ашказаны җәрәхәтләрен, югары сулыш юллары ялкынсынуын дәвалауда файдалы санала. Ашказаны һәм уникеилле эчәк җәрәхәтләре булганда сырганак маен 3-4 атна дәвамында, көнгә 3 тапкыр, ашар алдыннан берәр чәй кашыгы эчәргә кирәк. Сару кайнауны көчәйтмәсен өчен, майга 2 процентлы чәй содасы өстәп болгатырга була. Гинекологик авырулар вакытында сырганак мае тампон рәвешендә кулланыла. Экзема, тәңкәле тимрәү, хейлит (ирен ялкынсынуы) кебек тире авырулары вакытында көнгә 2 мл сырганак мае эчү яки мазь рәвешендә тирегә ягу да файда китерә. Үт куыгы кискен ялкынсынганда һәм ашказаны асты бизе авырулары булганда сырганак маен эчәргә ярамый. Сырганак маен ике юл белән әзерләргә мөмкин: җимешләрдән согын сыгып алалар һәм салкын урынга куеп торалар. Бераздан өскә калкып чыккан майны җыеп алырга була. Мондый юл белән алынган май сыйфатлырак санала. Яки согын сыкканнан соң калган түпне (жмых) ваклыйлар, үсемлек мае салып төнәтәләр һәм сөзәләр.


**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**



**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45



* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.



**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru



Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**

* * *


Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *


Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**

**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**

**график буенча**
**12 декабрь 16 сәг.**
**фактта 12 декабрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**